РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА БУГУЛЬМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.09.2016 г.Бугульма № 1157

# Балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен алу буенча алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

“Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2014 елның 1 декабрендәге 419 номерлы Федераль законның 26 маддәсенең 4 өлешенең 2 пункты нигезендә:

1. Балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен алу буенча алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.14 Пунктының 2 бүлеген яңа редакциядә укырга: “Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге, шул исәптән объектларга киртәләрсез керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин итергә. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла”.

2. Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүмати технологияләр бүлегенә әлеге карар кабул ителгәннән соң, 3 эш көне эчендә аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә – Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары М.Р. Болгаковка йөкләргә.

Җитәкче А.Р. Галиуллин